**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге**
**Иске Авыл торак пункты**
**гражданнар җыены КАРАРЫ**

«01» ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Иске Авыл торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Иске Авыл торак пунктында төзелеш контроле өчен түләү белән, сезонлы карап тоту.

2) Кара Күл торак пунктында күперне ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева